Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Советы карары

2016 елның 14 декабрь № 34

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегенең 2017 елга һәм 2018, 2019 елларның план чорына бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Олы Бортас авыл җирлеге Уставының 80, 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлегенең 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына (1А номерлы кушымта) бюджетын кабул итәргә.
2. ТР, Кама Тамагы районы, Олы Бортас авылы, Ленинград урамы, 27 йорт, ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин урамы, 70 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат щитларында әлеге карарны игълан итәргә һәм Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы Р.С.Сәгьдиевка йөкләргә.

Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы,
Олы Бортас авыл җирлеге Советы Рәисе Р.С.Сәгьдиев